**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Урсай авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№143** **28.05.2019 ел**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Советы карар проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның фикер алышуда катнашу тәртибе хакында**

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Советы карар проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен 1 кушымта нигезендә расларга.
2. Бу хакта мәгълүмати стендка элү юлы белән халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **Н.Ә. Гатина**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Урсай авыл җирлеге Советының
2019 елның 28 маендагы 143
номерлы карарына 1 кушымта

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Советы карар проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның фикер алышуда катнашу тәртибе**

l. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында карар проекты буенча тәкъдимнәр язмача формада Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге Советына түбәндәге адрес буенча бирелә: 423535, Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Урсай авылы, Үзәк ур., 5 й.

Тәкъдимнәр эш көннәрендә иртәнге 8.00дән 16.00 сәгатькә кадәр халыкка игълан ителгән көннән кабул ителә.

2. Чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча шәхсән китерелә яисә почта аша җибәрелә: 423535, Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Урсай авылы, Үзәк урам, 5 й.(конвертта “Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проекты буенча фикер алышу” дигән тамга белән).